СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«КАРКАЛИ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«КЕРКӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2026 елның 2 марты №4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 3 октябрендәге 13 номерлы карары преамбуласына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга»;

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 3 октябрендәге 13 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта:

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар белән« сүзләрен «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законнар белән» сүзләренә алмаштырырга.

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законнары белән» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»25.06.2013 №50-ТРЗ» сүзләренә алмаштырырга;

2) 9.1 пунктында 1 һәм 2 абзацларны түбәндәгечә үзгәртергә:

«9.1. Муниципаль хезмәт урынын биләүгә дәгъва кылучы гражданин, муниципаль хезмәткәр эш бирүче вәкиленә (эш бирүчегә) 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган очракларда керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыра. Әлеге мәгълүматлар 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшыру тәртибе, сроклары һәм формасы буенча тапшырыла.

Муниципаль хезмәт урынын биләүче муниципаль хезмәткәр, тиешле исемлеккә кертелгән, 2012 елның 3 декабрендә кабул ителгән №230-ФЗ «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән тәртип һәм форма буенча тапшырырга бурычлы.»;

3) 9.2 пунктында «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 9.3 пунктында «керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге мәкаләгә туры китереп бирелә торган мәгълүматлар» сүзләре белән алыштырырга;

5) 9.4 пунктында «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге мәкаләгә туры китереп бирелә торган мәгълүматлар» сүзләре белән алыштырырга;

6) 9.5 пунктында «үз керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре, шулай ук үзенең хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар» сүзләрен «25 декабрь 2008 ел, № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон белән каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, һәм 3 декабрь 2012 ел, № 230-ФЗ «Дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон белән каралган чыгымнар турында мәгълүматлар» сүзләренә алыштырырга;

7) 9.9 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«9.9 Контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүгә дәгъва итүче гражданнар, әлеге бүлекнең 9.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны тәкъдим итәләр, ә мондый вазифаны биләүче зат Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) мәгълүматларны тәкъдим итә.»;

8) 9.10 пунктын гамәлдән чыккан дип танырга;

9) 10 бүлекнең 10.1.3 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«10) 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Советская урамы, 95 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам

«Керкәле авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.И.Бигманов